Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«20» ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Бәтке» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Бәтке авылы Гагарин, Үзәк, Новая урамнары буенча күпфатирлы йортларның янәшә территорияләрен төзекләндерү (вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, алып кайту, җәю)
- Бәтке авылы канализация системасын ремонтлау
- «Зеленый островок» («Яшел утрау») паркы территориясен төзекләндерү (газон чабу, сәхнәне, эскәмияләрне буяу)
- Бәтке авылы юлларын ремонтлау
- Бәтке авылы Үзәк урамы буенча тротуарны төзекләндерү эшләрен башкару
- күпфатирлы йортлар территориясен төзекләндерү (койма сатып алу һәм урнаштыру, яшелләндерү)
- Бәтке авылы зиратында агачларны кисү
- Бәтке авылында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру
- Бәтке авылы тротуарны төзекләндерү эшләрен башкару
- Бәтке авылы Колхоз урамы территориясен төзекләндерү (грунт кертү, яшелләндерү)

2. Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы В.А.Валиева